КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 11 февраль г.Казань № 70

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Инвалидларны реабили-тацияләүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программалары нигезендә инвалидларга хезмәт шартларын тудыру тәртибен раслау турында» 2017 ел, 30 декабрь, 1132 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Инвалидларны реабили-тацияләүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программалары нигезендә инвалидларга хезмәт шартларын тудыру тәртибен раслау турында» 2017 ел, 30 декабрь, 1132 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 1 ноябрь, 1395 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль законның 20 статьясы белән» сүзләрен «Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 2023 елның 12 декабрендәге 565-ФЗ номерлы Федераль законның 37 статьясы белән» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Инвалидларны реабилитацияләүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программалары нигезендә инвалидларга хезмәт шартларын тудыру тәртибендә:

1 пунктта «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль законның 20 статьясы белән» сүзләрен «Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 2023 елның 12 декабрендәге 565-ФЗ номерлы Федераль законның 37 статьясы белән» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Бу Тәртипне гамәлгә ашыру  максатларында түбәндәге төшенчәләр һәм терминнар кулланыла:

инвалидларны эшкә урнаштыру өчен махсус эш урыннары - инвалидларның индивидуаль мөмкинлекләрен исәпкә алып, төп һәм ярдәмче җиһазларны, техник һәм оештыру җиһазларын, өстәмә җиһазлауны һәм техник җайланмалар белән тәэмин итүне дә кертеп, эшкә яраклаштыруны таләп итә торган хезмәтне оештыру буенча өстәмә чаралар таләп итә торган эш урыннары (алга таба - махсус эш урыннары);

инвалидны тернәкләндерүнең һәм абилитацияләүнең индивидуаль программасы - инвалидларны комплекслы тернәкләндерүнең һәм  абилитацияләүнең төп юнәлешләре буенча, мондый чараларны гамәлгә ашыру срокларын һәм тәртибен, комплекслы тернәкләндерү һәм абилитацияләүнең максатын күздә тота һәм организмның бозылган функцияләрен торгызуга,  инвалидның билгеле бер эшчәнлек төрләрен башкаруга сәләтләрен компенсацияләүгә юнәлдерелгән инвалидлар өчен оптималь чаралар һәм хезмәт күрсәтүләр комплексы.

Әлеге Тәртиптә кулланыла торган башка төшенчәләр һәм терминнар «Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 2023 елның 12 декабрендәге 565-ФЗ номерлы Федераль законда, «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән мәгънәләрдә кулланыла.»;

7 пунктның икенче абзацында «хезмәт куркынычсызлыгы» сүзләрен «хезмәтне саклауның дәүләт норматив таләпләренә туры килә торган хезмәт куркынычсызлыгы һәм шартлары» сүзләренә алмаштырырга;

9 пунктта:

икенче абзацта «вазыйфалар» сүзеннән соң «яисә һөнәрләр» сүзләрен өстәргә;

өченче абзацта «, тәгаен вазыйфаларны яисә һөнәрләрне күрсәтеп, төзелгән яисә бүлеп бирелгән эш урыннары саны» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә, әлеге карарның  2025 елның 1 мартыннан үз көченә керә торган 1 пунктының сигезенче абзацыннан тыш.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин